**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
04.09.2024

КАРАР
№ 1003

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә бәйрәм иҗтимагый-сәяси, мәдәни-массакүләм һәм спорт-массакүләм чаралар уздырганда сәүдә оештыру турында» 2022 елның 03 мартындагы 239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 03 мартындагы 239 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә бәйрәм иҗтимагый-сәяси, мәдәни-массакүләм һәм спорт-массакүләм чаралар уздырганда сәүдәне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Күчмә сәүдәне оештыру турындагы хәбәрнамәгә кушымтада «МП» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. 1нче кушымтаның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. "Һөнәри керемгә салым" махсус салым режимын кулланучы, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән оешмалар, индивидуаль эшкуарлар, физик затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) күчмә сәүдәдә катнашырга теләүчеләр Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә күчмә сәүдәдә катнашу өчен Башкарма комитет җитәкчесе исеменә белдерүгә кушымтада каралган рәвештә гариза җибәрәләр.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин